**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

ПР-41 06.03.2024

«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында физик культура һәм спорт өлкәсендә белем һәм күнекмәләр дәрәҗәсен бәяләүгә карата сынау (тестлар), нормативлар, таләпләр төрләрен үтәү буенча тест үткәрү үзәген булдыру турында» 2015 елның 22 июнендәге ПР-64 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

1. «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында физик культура һәм спорт өлкәсендә белем һәм күнекмәләр дәрәҗәсен бәяләүгә карата сынау (тестлар), нормативлар, таләпләр төрләрен үтәү буенча тест үткәрү үзәген булдыру турында» 2015 елның 22 июнендәге ПР-64 номерлы Татарстан Республикасы Башкарма комитеты җитәкчесе карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

1.1. Бөтен текстта «Актаныш муниципаль районының балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү МБМУ сүзләрен «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Батыр» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 2 нче пунктта «Актаныш муниципаль районының «Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү МБМУ директоры Вәлиев Ленис Әнәс улын тест үткәрү үзәге җитәкчесе итеп билгеләргә (җитәкче вәкаләтләрен йөкләргә), җөмләсен «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Батыр» спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе директоры Гафуров Әнвәр Әбсөгыт улын тест үткәрү үзәге җитәкчесе итеп билгеләргә» җөмләсенә алмаштырырга.

1.3. 3 нче пунктта «Актаныш муниципаль районының балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе МБМУ директоры урынбасары Газетдинов Ренат Салават улын тест үткәрү үзәгенең баш хөкемдары итеп билгеләргә, җөмләсен «1 нче санлы Актаныш урта мәктәбенең тормыш иминлеге нигезләре укытучысы Хаҗиев Равил Фагитҗан улын тест үткәрү үзәгенең баш хөкемдары итеп билгеләргә җөмләсенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында: http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.М. Әнвәровага йөкләргә.

Җитәкче Р.А.Ильясов